СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

18 апрель, 1997 ел. ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 43 (8055) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Сез дә оттыгыз, без дә шат

***Мәгълүм булганча, апрельнең беренче унконлегендә «Дуслык» («Дружба», «Туслах») район газетасына льготалы язылу игълан ителгән иде. Аның нәтиҗәсе без көткәннән дә яхшырак булып чыкты.*** **Ун көн эчендә район газетасына 8 меңгә якын гаилә язылды.** ***Кайчагында өч айлык язылу кампаниясе дәвамында да шулкадәр әбунәче җыя алмый идек.***

***Билгеле, безнең хезмәттәшләребез һәм якын булышчыларыбыз - элемтәчеләрнең теләгеннән һәм ярдәменнән башка мондый нәтиҗәгә ирешү мөмкин булмас иде. Шуңа да без район элемтә узелы җитәкчелегенә һәм подписка бүлегенә, шәһәрдәге һәм авыллардагы элемтә бүлекләре хезмәткәрләренә, шул исәптән хат ташучыларга бу киеренке эшне шулай нәтиҗәле итеп үткәргәннәре өчен зур рәхмәт әйтәбез. Район газетасы белән дуслыкларын алга таба да өзмәскә булган күптәнге укучыларыбызга, безнең әбунәчеләребез сафына яңа гына кушылганнарга да олы рәхмәт хисләребезне җиткерәбез. Үз чиратыбызда без сезнең ышанычыгызны аклау өчен бар тырышлыгыбызны куярга вәгъдә бирәбез. Газетабызны теләп алдыручыларның шулай күп булуы безне алга таба тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә рухландыра. Болай булгач, яшибез икән әле!***

***Хөрмәт белән***
***район газетасы редколлегиясе.***

***Ә район газетасына язылу дәвам итә.***

## Сессия чакырыла

Халык депутатларының XXII чакырылыш район Советының 10 нчы сессиясе быелның 21 апрелендә иртәнге сәгать 9да район хакимиятенең утырышлар залында ачыла.

## ТАТАР КОНГРЕССЫНА ӘЗЕРЛЕК БАРА

**Татарстан Премьер - Министры Фәрит Мөхәммәтшин икенче Бөтендөнья татар конгрессына әзерлек буенча оештыру комитеты утырышын үткәрде.**

Анда Дәүләт һәм Россия төбәкләре җитәкчеләренә бу эшне оештыруда булышлык күрсәтүне сорап хатлар җибәрү турында карар кабул ителде.

29 августта уздырылачак форумның үзеннән тыш, аннан элегрәк фәнни - практик конференция һәм төрле темалар буенча «Түгәрәк өстәл»ләр булачак. Конгресс көннәрендә «Татар дөньясы», «Кубрат хан хәзинәләре» дигән күргәзмәләр оештырылыр, республика сәнгать осталары концерты булыр һәм башка чаралар үткәрелер.

30 августта конгресс делегатлары һәм кунаклары Татарстан суверенитеты көнен бәйрәм итүдә катнашырлар.

Утырышта конгрессны әзерләү һәм үткәрүнең башка мәсьәләләре дә тикшерелде.

## Хезмәтләре белән мактаулылар



Норлат электр белән тәэмин итү районы. Бу зур булмаган коллективның төп бурычы - поездларның төгәл хәрәкәтен тәэмин итү өчен өзлексез энергия бирү. Дежур электромонтер Галина Павловна Казакова исә энергияне вакытында тоташтырып - өзеп торырга, тегe яки бу өзеклекләр булганда кичекмәстән хәбәр бирергә тиеш. 5 елдан артык эшләү дәверендә Галина Павловна хезмәтен ныклап үзләштерергә өлгерде инде. Монда коллективның иң тәҗрибәле электромонтеры Владимир Иванович Мытаревның да өлеше зур булды. 30 елдан артык эшләү дәверендә ул дистәдән артык яшь эшчегә хезмәт серләрен өйрәтте. Хәзер исә хезмәтен уңышлы гына алып баручы Г.П.Казаковага карап та шатлана ул.

**Рәсемдә: дежур электромонтер Г.П.Казакова.**

## Кырга чыгарга әзерләр

Хафизов исемендәге крестьян - фермер хуҗалыгы ассоциациясе язгы кыр эшләренә нигездә беренчеләр сафында керешә һәм бу мөһим кампанияне тиз арада тәмамлый да. Механизаторлар быел да сер бирмәскә ниятлиләр. Бүгенге көндә язын кырда эшләячәк техниканың барысы да сафта. Авыл хуҗалыгы машиналары агрегатлаштырылган. Тракторлар да бүгеннән басуга чыгарга әзер. Әле күптән түгел хуҗалыкта техниканың хәзерлеген тикшерү максатында бригадалар арасында үткән үзара тикшерү нәтиҗәләре дә шуны раслады.

Әйе, язгы кыр эшләре башланыр көннәргә күп вакыт калмады. Хафизовлыларның бу кампанияне һәръяклы хәзерлек белән каршылаулары шатландыра. Механизаторларның язгы чәчүне оешкан төстә үткәреп, быелгы уңышка ныклы нигез салуларына да өметне ныгыта.

**С.ФӘЙЗУЛЛИНА.**

## Бәрәкәтле беренче чирек

**Инде хәбәр иткәнебезчә, 12 апрельдә узган киңәшмәдә беренче эш итеп сүз район терлекчеләренең беренче кварталдагы эш йомгакларына багышланды. Ул турыда информацияне авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге начальнигы Ф.Г.Минһаҗев ясады.**

Шунысы куанычлы, яңа елның беренче чирегe терлекчелекнең барлык юнәлешләрендә дә бәрәкәтле булды. Сөт җитештерүчеләрнең узган кварталда ничек эшләгәнлекләре турында газетада мәгълүматлар бирелде инде. Өстәп өч айда узган елның шул чорындагыдан сөтнең тулаем 27 процентка күбрәк савылуын, аны сату буенча план-заказның 158 процентка үтәлүен генә әйтергә кирәк.

Ә сөт җитештерүнең артуына китергән факторлар арасында сыерлардан үрчем алу эшенең сизелерлек яхшыруын билгеләп үтми мөмкин түгел. Район буенча йөз сыерга 35 бозау алынды һәм бу узган елгыдан биш башка артыграк. Мичурин исемендәге КХАда һәм «Дуслык»та йөз сыерга 62шәр бозау алынды һәм былтыргыдан үсеш тә зур. РСУның «Мамык» ярдәмче хуҗалыгында һәм «Якты Күл»дә бу күрсәткеч 54 - 56, «Кондырча», «Чирмешән» һәм «Тәрнәс»тә 48-49 баш булды, өстәвенә, күбесендә бу күрсәткечләр узган елгыдан яхшырак. Ә менә Хафизов исемендәге, «Родина», «40 лет Победы» хуҗалыкларында бозау алу йөз сыерга күчереп исәпләгәндә утызга да тулмый һәм былтыргыга караганда чигенеш тә шактый - 10 - 13 баш. Ә инде «Агрохимсервис»ның «Сөлчә» ярдәмче хуҗалыгында беренче кварталда йөз сыерга нибары...17шәр бозау белән калдылар, узган елгы нәтиҗәләреннән 23 башка чигенеш ясадылар.

Шунысы игътибарга лаек, быел бозауны күп алган хуҗалыкларның барысында да аларны салкында асрау технологиясен кыю төстә киң кулланулары мәгълүм. Димәк, яңалыкның нигезле булуына шикләнмәскә мөмкин. Аннары салкында асрау яшь малларның яхшы саклануына ирешүдә дә мөһим алшарт булып тора. Һәм район буенча бу кварталда мөгезле эре терлекләрнең үлеме узган елгыдан шактый ук азрак булуы тикмәгә түгел. Технология таләпләрен җиренә җиткереп үтәүнең уңай нәтиҗәсе маллардан артым алуда да ачык чагыла. Район буенча мөгезле эре терлекләрнең тәүлеклек үсеше 467 грамм булу инде һич тә начар күрсәткеч түгел. Синдряков исемендәге, «Алга», «Рассвет», «Якты Күл» хуҗалыкларында бу күрсәткеч ярты килодан артыграк, «Таң»да һәм шикәр заводының «Восход» ярдәмче хуҗалыгында 600 граммнан күбрәк булды. Бу җәһәттән яшь малларны салкында асрау белән беррәттән, ташлаткан һәм бозаулаган сыерларны аерып махсус рацион буенча ашату, симертүдәгеләрен яшь һәм җенес буенча группаларга бүлүгә зур әһәмият бирелүен дә әйтергә кирәк. (Һәм шушы киңәшмә көнне Мичурин исемендәге, «Кикле» КХАларында, сөт - май комбинаты һәм шикәр заводының ярдәмче хуҗалыкларында булып терлекчелектә эшләрнең торышы белән танышканда, моннан элек, ноябрьдә Мамадыш, Балтач һәм Биектау районнарында терлекчелек фермаларын карап йөргәндә алардагыдай үрнәк тәртипнең бездә дә шулай тиз генә булдырылачагына ышану түгел, өметләнмәүчеләр дә булганлыгы турында уйлап куйдым. Баксаң, бер дә кешедән ким җиребез юк икән бит. Күңел иткәч, чынлап торып алынгач әнә кыска гына вакыт эчендә үзебездә дә башкаларга күрсәтерлек нәрсәләр бар хәзер).

Ит җитештерүдә мөһим тармак булган дуңгызчылыкта да беренче кварталда уңай үзгәрешләр шактый. Иң мөһиме - дуңгызларның гомуми баш саны 1410 га артты. Дөрес, район күләмендә алганда әле бу бик зур сан түгел. Ник дисәң, Синдряков исемендәге һәм Мичурин исемендәге хуҗалыкларның үзләрендә генә дә дуңгызларның баш саны 734 - 838 башка артты, «Рассвет»та да үсеш 500 башка якын. Ә менә Хафизов исемендәге хуҗалыкта бу төр малның баш саны 450 гә кимеде, гомер - гомергә бу тармакта эшләре әйбәт барган «40 лет Победы»да да чигенеш зур.

Билгеле, баш саны арту беренче чиратта үрчем алу хисабына бара һәм алда уңай яктан телгә алынган хуҗалыкларда бу күрсәткечләр дә чагыштырмача яхшы. Әйтик, Мичурин исемендәге, «Рассвет», Муса Җәлил исемендәге КХАларда йөз анага 800-886 дуңгыз баласы алынды, бу тармакта эш оештыруны яхшырткан «Заветы Ильича», «Үрнәк» КХАларында, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгында да алга китеш сизелерлек. Алда әйтелгәннәрнең нәтиҗәсе буларак, беренче кварталда ит җитештерү узган елның шул чорындагыдан 24 процентка артса, аны хәзерләү заказы 163 процентка башкарылды.

Терлекчелектә эшләрнең уңайлашуга баруын раслаучы мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Әмма ирешелгәннәр белән тынычланырга иртәрәк әле. Бигрәк тә хәзер, кышлатуның авырлык белән уза торган йомгаклау этабында тезгенне йомшарту һич тә ярамый.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## 2000 нче елга – полиомиелитсыз!

***Быелның апрель - маенда 3 айдан 3 яшькә кадәрге балаларны полиомиелитка каршы массовый иммунлаштыру, ягъни вакциналау буенча милли көннәр уздырыла. Бу уңайдан аңлатма бирүен үтенеп без Дәүләт санэпидкүзәтү үзәгенең эпидемиология бүлеге мөдире Татьяна Геннадьевна СОРЕНКОВАГА мөрәҗәгать иттек.***

- Поилиомиелит - я баланың үлеменә китерә, я аны гомерлек гарип итеп калдыра торган куркыныч йогышлы авыру. 1996 елда Татарстанда бу авырудан 5 бала үлде. Аларның берсенә дә прививка ясалмаган булган.

Массовый иммунлаштыру көннәре икенче ел уздырыла инде. Быел аның беренче туры **апрельнең 21 еннән 25 енә кадәр, икенчесе - майның 26 сыннан 31 енә** кадәр үтәчәк. Бу вакыт җылы көннәргә туры китереп махсус сайлап алынды. Балаларга прививка тору урыннарында - дәвалау учреждениеләрендә, балалар бакчаларында ясалачак. Нибары ике тамчы вакцина балагызны авырудан саклап калачак. Ул прививканың организмга ярамавы сәбәпләре юк диярлек. Балаларыгызны поиомиелитка каршы прививка ясатырга алып килми калмагыз - аларның сәламәтлеге турында кайгыртыгыз!

Газетаның киләсе саны 23 апрельдә чыга

# Авыл: Кичә. Бүген. Иртәгә.

# ШӘҺӘР АВЫЛНЫ КАЙГЫРТА

## Ике фронтка

**РСУның болай да тынгысыз тормышы бу көннәрдә тагын да тыгызланды: нигездә ремонт - төзелеш эшләре белән шөгыльләнгән төзелеш оешмасы ел башыннан «Мамык» крестьян хуҗалыклары ассоциациясен үзенә ярдәмче хуҗалык итеп алды. Төзелеш оешмасын 60 километрлы арадагы авыл белән «туганлык» җепләре бәйли хәзер.**

**- Бергә яшәргә насыйп булгач, кулга - кул тотынып ике фронтка эшләргә туры килә инде,- ди РСУ начальнигы, хәзер инде «Мамык»ның генераль директоры да С.Г.Мөлеков кәгазьләрен барлап.**

**- Бер эзгә төшкәнче җиңел булмас. Әмма ике арада мөнәсәбәтләр эшлекле һәм ике якка да файдага буласына бүген үк ышандыра алам,- ди «генеральный». Бу исемне Тимерлектә булганда еш ишетергә туры килде безгә: хөрмәт итеп, ышаныч белдереп әйтүләре чагылды бу сүзләрендә. Ышаныч дигәннән, мамыклылар ике арадагы мөнәсәбәтнең якынаюына шатлар: урман арасында берничә район чигендә урнашкан һәм гомер - гомергә район җитәкчелегенең күз уңыннан, ярдәменнән читтә кала килгән бу төбәккә дә ниһаять игътибар булыр икән.**

**Тимерлек - зур потенциаль мөмкинлекләргә ия төбәк. Әнә җирләрнең бонитеты түбән булу сәбәпле соңгы биш елда бөртекле һәм бөртекле - кузаклыларның һәр гектарыннан нибары 12,5 центнер уңыш җыйсалар, узган ел бу күрсәткеч ике тапкыр үскән. Дәүләткә гомердә булмаган күләмдә - 11.400 центнер ашлык сата алганнар. Дәүләт заказы үтәлгән. Хуҗалыкта моны соңгы елларда авылда эшләүче һәркемнең җиргә икенче төрле, хуҗаларча каравы белән бәйлиләр.**

**Терлекчелек продуктлары сату буенча да бурычлы калмаганнар мамыклылар.**

**- Халык эшчән бездә,- ди экономист Е.Максимов, уңышны билгеләүче тагын бер, аз әһәмияткә ия булмаган факторны ассызыклап. - Техникага үземнеке дип карау - бездә күптән ныгыган мөнәсәбәт.**

**Шулай икән шул. «Мамык»та механизаторлар техниканы яңа көе кабул итеп алалар да, ул гамәлдән чыкканчы хуҗасы үзгәрми. Быел кыш көнне үк барлык 14 йөк машинасы да төзәтелгән иде. Тракторлар, комбайннар белән дә шундый ук хәл. Соңгыларының, барысының да файдалану сроклары чыккан булуларына да карамастан, узган ел уракта һәркайсына төшкән уртача 238 гектар «нагрузка»ны үтәп, «Путь к коммунизму» КХАнә ярдәмгә барулары үзе үк күп нәрсә турында сөйли.**

**Шул ук вакытта хуҗалыкта беренче чиратта хәл итүне көтүче проблемалар да бихисап.**

## Кем нәрсә ота?

- Төзүчеләрдән ярдәм, хезмәтне оештыруда дөрес юнәлеш булса, эшләү, тырышлык бездән калмас,- диләр авыл эшчәннәре. Ул яктан РСУлар үзләрен «кысып» булса да авыл эшчәннәренә хезмәт хакы түләү мәсьәләсен хәл иткәннәр: быелның гыйнвар ае ведомостен тулысынча япканнар. Озакламый кырга чыгачак техниканы төзәтеп бетерү өчен дә финанс тапканнар төзүчеләр. 60 миллион сумлык төзелеш материалы да Тимерлек складына күчкән. Авыл халкына хезмәт хакы исәбенә дә алу мөмкин булачак аны. Кыл да кыймылдатылмаган газлаштыру эшенә дә «җан» кергән: проектлар әзерләнә. Төзелгәннән бирле капиталь ремонтланмаган мәктәп тә быел РСУ осталары кулы тигәч, яңа кыяфәткә керер мөгаен. Ашханә, фельдшерлык пункты да үзгәрергә тора. «Сакаллы» объект саналган мастерскойда бүген үк инде кызу эш кайный. «Генеральный» биредәге иң яхшы бүлмәләрне мич ягып җылытыла торган иске конторага алмашка бирергә боерган. Терлекчелек объектларын реконструкцияләү дә планга кертелгән. Быел җәй үк хуҗалыкта яхшы эшләүче өч терлекчегә йорт салып бирүне дә реаль мөмкинлек дип саныйлар төзүчеләр. Болар өстенә РСУ «Мамык»та җыйнак кына пекарня һәм тегермән, идарәнең тегү һәм столярлык цехлары филиалларын ачу буенча планнарын да тормышка ашырса, якын киләчәктә Тимерлек төбәгенең чәчәк атасына өмет тагын да ныгый. Аннары район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да Елаур, Тимерлек халкы белән сайлау алды очрашуында бу төбәкне күтәрү өчен хәлдән килгәннең барысын да эшләргә вәгъдә биргән иде бит. Вәгъдә - иман, ди халык. Димәк, «Мамык»ка ярдәм РСУдан тыш, районнан да булачак әле.

Идарәнең бу «туганлыктан» нәрсә отуын исә күзалларга гына була әлегә. Шуңа да биредә уенын - чынын бергә кушып: әлегә эш кенә, диләр. Әйе, эш фронтына һичкайчан аптырамаган идарә өчен ул тагын да киңәйде. Биредән Тимерлеккә белгечләр, эшчеләр китмәгән көн юк хәзер. «Кесә»не дә икегә бүлмичә булмый. Хуҗалыкны аякка бастыру, оештыру моментында шунсыз мөмкин дә түгел, дип саныйлар РСУда.

- Килер бер көн, ярдәмче хуҗалыгыбыз үк туендыра да башлар үзебезне,- дип ышаныч белдерә С.Г.Мөлеков. - Әлегәчә ярдәм һәм тагын бер кат ярдәм итеп, авыл халкын үз җирендә хуҗа буларак хуҗалык итәргә өйрәтәсе бар әле.

## Кемлекләрен күрсәтерләр әле

Хуҗа дигәннән, Тимерлек халкын эшчән дип никадәр мактасак та, араларындагы сорыкортларга тиң, җәмәгать милкен урлап яисә башкача кеше җилкәсендә көн күрергә яратучылар да юк түгел. Шуңа да эшләгән генә ашарга тиеш дигән принциптан чыгып, хуҗалык итүнең яңа алымын - кооператив системасын сайлаганнар. Алдынгы хуҗалыклар тәҗрибәсен өйрәнү максатында Биектау районында да булганнар, районыбызның «Москва», «Заря» хуҗалыклары эш тәҗрибәсе белән дә танышканнар. Киңәшкәннәр, сөйләшкәннәр, барлык плюс, минусларны барлап, исәп - хисап та ясап караганнар. Инде җир пайларга бүленгән, барлыгы 451 хуҗага тапшырылган. Шулар нигезендә 4 кооператив оешкан. Башка хуҗалыклардагыдан үзгә буларак, биредә бер кооператив өстәмә эш итеп яшелчәчелек белән шөгыльләнүне дә алган. Ашханәне бәрәңге, кәбестә, чөгендер һ.б. белән алар тәэмин итәчәк. Ә инде яшелчә саклагычлар төзүне РСУ беренчел бурыч итеп билгеләгән.

Кыскасы, боз урыныннан кузгалган. Әмма бу гына аз әле. Нәсел эшенең озак еллар буена үзагымга куелуы, бүгеннән торып, тотрыклы рәвештә продукция җитештерә башлауга мөмкинлекне чикли. Бүген үк нәселле терлек кайтартыр идең, акчасы юк... Халыкка мөрәҗәгать белән чыгудан да кулайрак юл тапмаганнар җитәкчеләр: сөтле сыерлардан туган бозауларны фермадагы үгез бозаулар яисә ит юнәлешле яшь терлеккә алыштырырга мөмкин. РСУның нәселле дуңгызлар кайтарту планы да барып чыгарга тиеш.

Соңгы вакытта тезген йомшару сәбәпле хуҗалык өчен зыяннан кала һич нәрсәсе булмаган умартачылыкта да быел 8 аренда звеносы оешкан. Һәрберсендә 100 баш умарта гаиләсе бар. Арендаторларга аларның һәркайсыннан 12шәр килограмм бал тапшыру бурычы куелган. Шуннан артыграгы үзләренә. Барысы да хуҗа, алай гына да түгел, нинди хуҗа - бәрәкәтле, берәмтекләме, сансызмы - шуңа бәйле булачак. Ахыр чиктә яңача хуҗалык итү, кооперативлар нигезенә дә шул принцип салынган бит: чыгымнарга каршы механизмны хәрәкәткә җибәреп, хәләл көчең белән табылган керемеңне тиенендә кадәр санап тоту, гомумән, минеке дип, чын хуҗа булып яшәү.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Олег белән Ольга



*Аларның бергә тормыш коруларына ике еллап кына әле. Җәен хатыны ашханәдә, ире исә ГАЗ - 53 автомашинасында эшли. Икесе дә тырышлар, булдыклылар. Кышларын фермада маллар караучы Олег быел хатыны Ольганы да үзе янына эшкә алды. Хезмәтләре җаваплы аларның: яңа туган бозауларны исән - имин үстерим дисәң, яшь бала караган кебек карарга, тәрбияләргә кирәк аларны. Бозауларны эчәргә өйрәтү, азыкка күнектерү генә дә нинди зур тырышлык таләп итә бит. Өстәвенә, быел бозаулар яңа ысул буенча салкында асрала. Захаровлар хуҗалыкта бу эшкә нигез салучылар булдылар. Яңалык авырлык белән тормышка ашырылса да, Олег белән Ольга үзләреннән торганның барысын да эшлиләр. Малларның тәүлек саен уртача 800 - 850 граммга артуы, үлем - китемнең юк дәрәҗәсендә булуы да шул хакта сөйли.*

**Безнең фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ «Мамык» күмәк хуҗалыгы терлекчеләре Захаровларны эш вакытында рәсемгә төшереп алган.**

## Россиянең сугышчан дан көннәре



***18 апрель - Александр Невский җитәкчелегендәге рус сугышчыларының Чуд күлендә немец рыцарьларын җиңүе көне (1242 елгы Боз өсте сугышы).***

Бу сугышта Александр Невский зек акыллы хәрби начальник осталыгын күрсәтә. Ул рус гаскәрләрен күлнең иң тар урынына урнаштырып, дошманны үзе сайлап алган урында сугышырга мәҗбүр итә.

Чуд күлендә җиңү гаять зур тарихи әһәмияткә ия була: ул рус җирен буйсындыруны максат итеп куйган тәре йөртүчеләрнең көнчыгышка хәрәкәтен туктата.

## Шәһәребез урамнары алар исемен йөртә

***Норлатка нигез салынуы һәм аның үсеше Советлар Союзы барлыкка килүе һәм үсеше белән берьюлы барды. Шуңа күрә ул чордагы вакыйгалар, сәяси атмосфера яңа төзелгән урамнарның исемнәрендә чагылуы аңлашыла да. Аларга партия, хөкүмәт җитәкчеләре, карт революционерлар исемнәре бирелә. Кайберләрен, мәсәлән,***

## Леонид Красин урамын



өлкәнрәк буын кешеләре дә хәтерлиләрдер, мөгаен.

Леонид Борисович Красин (1870 - 1926) Коммунистлар партиясенең иң өлкән әгъзасы. Күренекле совет дипломанты. 1887 елда Петербург техник институтына укырга керә, студент чагында ук революцион хәрәкәткә кушыла. 1891 елда демонстрациядә катнашканы өчен институттан куыла һәм Петербургтан Түбән Новгородка сөргенгә җибәрелә.

1892 - 94 елларда берничә тапкыр кулга алына. 1895тә өч елга Иркутск шәһәренә сөрелә. Сөрген срогын тутырганнан соң Харьков технологик институтына укырга керә һәм аны 1900нчы елда тәмамлый.

1900 - 1904 елларда Бакуда инженер булып эшли. Партия эшен башкара, РСДРПның II - III һәм IV съездларында катнаша. Үзәк комитет әгъзасы булып сайлана. Большевикларның «Новая жизнь» (1905) газетасын оештыручы да ул. 1908 елда чит илгә китә, «Алга» группасына керә, инженер булып эшли.

Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң сәүдә һәм промышленность буенча халык комиссары булып билгеләнә, 1919 елда ул дипломатик эшкә. Эстония белән тыныч килешүләр алып баручы делегация әгъзасы була. 1921 - 1923 елда тышкы сәүдә халык комиссары һәм шул ук вакытта Лондонда сәүдә буенча вәкил вазифаларын да башкара. Генуя һәм Гаагада халыкара конференцияләрдә катнаша. 1924 елда Франциядә полпред, 1925тә Англиядә полпред булып тора. Партиянең XIII һәм XIV съездларында катнаша, ҮК әгъзасы.

1926 елда Мәскәүдә Кремль стенасы каршында Кызыл мәйданда күмелә.

**Рубриканы И.САНДЛЕР алып бара.**

### Мәктәпләрдән язалар

## Санкт - Петербургта булдык

Мәктәп еллары гомергә истә кала. Ул чорда поход, экскурсияләрдә үткән көннәр дә истән чыкмый. Мәсәлән, күптән түгел Санкт - Петербургка барып кайтуыбыз онытылырлыкмыни? Дөрес, бу каланың гүзәллеге турында моңа кадәр дә ишетергә туры килгән иде. Әмма үз күзләрең белән күрү мең кат ишетүдән күпкә яхшырак икән. Исакий һәм Екатерина соборлары, Эрмитаж, Кунсткамера, төрле музейларда булу безгә бик ошады. Нева проспекты буйлап җәяүләп йөредек, Петропавловск крепостеннән көн уртасындагы атуны тыңладык, теләкләр теләдек. Әгәр дә инде аларны берничәне теләү мөмкинлеге булса, һичшиксез бирегә тагын да килергә теләвебез турында булыр иде ул.

Әлеге экскурсия вакытында без үзебезнең коллективны ныклыкка сынадык, үзара мөнәсәбәтләрнең нәрсә икәнен белдек, кешеләр белән аралашу һәм үз - үзеңне тоту буенча бай дәрес алдык, яхшылык эшләү, үзара аңлашу, кунакчыллыкның нәрсә икәнлеген исебездә калдырдык. Шуңа да мин группа исеменнән шушы авыр, акчасызлык заманында безне Санкт - Петербургка җибәрү мөмкинлеге тапкан ата - аналарыбызга, үзебезгә ышаныч күрсәтеп, күптән күңелебездә йөргән хыялыбызны тормышка ашыруда ярдәм күрсәткән укытучыларыбыз Ольга Васильевна Ханнанова, Татьяна Тимофеевна Суслова, Надежда Васильевна Коннова, мәктәп дирекциясенә олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

**Т.КОПАНЕВА, шәһәрнең икенче урта мәктәбе укучысы.**